СОВЕТ
ЧУТЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
ЧҮТИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

15.03.2022 ел Чүти ав. № 36

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Чүти авыл җирлеге Советының 2017 елның 07 августындагы 18 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Чүти авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны һәм контракт буенча башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтта урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларында бастыру өчен тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 31 июлендәге 259-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Кайбыч муниципаль районы Чүти авыл җирлегенең Чүти авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Чүти авыл җирлеге Советының 2017 елның 07 августындагы 18 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Чүти авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны һәм контракт буенча башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтта урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларында бастыру өчен тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктның г пунктчасында «оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы пайлар,» сүзләреннән соң «цифрлы финанс активлары, цифрлы валюталар,» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Кайбыч муниципаль районы Чүти авыл җирлегенең http://chuteev-kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча рәсми сайтында бастырырга.

Совет Рәисе,
Кайбыч муниципаль районы
Чүти авыл җирлеге Башлыгы П.П.Тараканов